# Бәрәңгегә ни булган?

## Эссе җәйнең тагын бер галәмәте – җир астындагы яңа бәрәңгеләрнең үрентеләре барлыкка килгән

**56 еллык җир белән эшләү тәҗрибәсе булган Мөхәррәм абый Мөхәммәтҗановка халык шул турыда борчылып яза башлагач, ул да үзенең бәрәңгеләрен казып караган.**



ФОТО: TATAR-INFORM.RU

Сүз уңаеннан: Мөхәррәм абый – Буа районы, Яңа Тинчәле авылының легендар колхоз рәисе. Лаеклы ялда бакча эшләре белән мәшгуль. Инстаграмдагы сәхифәсендә үзенең тормышы, хезмәт юлы белән бәйле тарихи истәлекләрне барлый. Бакчачыларга киңәшләрен дә биреп бара. Бу юлы да халыктан килгән сорауларга битараф калмаган иде.

Мөхәррәм абый әйтүенчә, 2010 елның җәендә дә шундый ук хәл күзәтелгән булган.

– Кайбер бәрәңгеләрдә чынлап та үрентеләр күренә, хәтта яшел яфраклары да чыга башлаган. Бөтен районнарда да шул хәл дип әйтеп булмыйдыр, төрле җирдә туфрак төрлечә өлгерә һәм бәрәңге утырту вакыты шуңа карап көйләнә. Аннары безнең якларда туфрак та кара. Казан арты яклары белән чагыштырганда, без гомер буена бәрәңгене дә атна-ун көнгә иртәрәк утыртабыз. Быел 28 апрельдә үк утырттык. Җәй коры килде, көннәр дә һаман эссе тора. Аномаль һава торышы сәбәпле, бәрәңге дә икенче тапкыр уңыш бирергә омтыла. Бәрәңге алырга әле 20-25 көн бар. Сабакларын чабып атып булмый, чөнки алар әле ямь-яшел булып утыра. Үсеп бетмәгән бәрәңгеләре дә бар әле. Көзгә бәрәңге алганда, үрентесе булганнарны чәчүлеккә калдырырга киңәш итмим, үргән сабакларын сындырып атып, ашага тотыгыз яки терлекләргә бирегез. Черемичә кыш чыгар дип фаразласак та, бер сабак чыгарган куздән яңа үсенте булмаячак, – ди ул.

Мөхәррәм абый үзе икенче бер вариантны да кулланып карарга җыена. Алар яңа бәрәңгене 20 июньнән үк ашыйлар икән инде. Ашау өчен, балаларга да биреп җибәрү өчен казып, алганда чыккан үрентеле бәрәңгеләрне суганнан бушап калган түтәлгә утыртырга булганнар. Октябрь башына алар 30-40 граммлы булып үсәргә өлгерәчәк һәм чәчүлек өчен менә дигән материал да булачак икән.

– Бәрәңге үстерү белән шөгыльләнүче хуҗалыклар шулай эшли дә дип беләм. Чөнки чиста бәрәңге орлыгы үстерү технологиясе җәй уртасында бәрәңге утыртуга нигезләнгән. Бер төптән ун-унике бәрәңге чыга, сайлап чүплисе дә юк. Барысын да чәчүлеккә салып куясың, – ди тәҗрибәле агроном.

Быел яңгырлар булмагач, бәрәңге уңышы начар булыр дип борчыла халык. Киләсе ел өчен булса да Мөхәррәм абый бер киңәшен бирде. Корылыкка чыдам «Ажур» сортлы бәрәңге утыртырга кушты ул. Берничә төрле сортны сынаганнан соң, үзе шул сортны гына калдырган.

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# Вак акчаңны китер...

## Кредит оешмалары тарафыннан Россия банкы тәңкәләрен кабул итү турында.

**Соңгы вакытта финанс хезмәтләреннән файдаланучылардан Россия Банкына аерым кредит оешмалары тарафыннан банк счетына язып куйган һәм акча күчергән өчен Россия Банкы тәңкәләрен кабул итү һәм яңадан санау хезмәтенә комиссион түләү билгеләү турында мөрәҗәгатьләр килде. Шуңа бәйле рәвештә, Россия Банкы 2021 елның 10 июнендә ИН-06-59/38 санлы мәгълүмати хат таратты.**




Хатта хәбәр ителгәнчә, «Россия Федерациясенең Үзәк банкы (Россия Банкы) турында»гы Федераль законның 30нчы маддәсе нигезендә, Россия Банкы банкнотлары һәм тәңкәләре түләүләрнең барлык төрләрен башкарган, счетларга, кертемнәргә язып кую һәм Россия Федерациясе территориясендә күчерү өчен күрсәтелгән хакы буенча кабул ителергә тиеш. Бу банкның вазифасы булып тора һәм клиент тарафыннан ниндидер каршы җавапны таләп итми.

Шулай ук Россия Банкы тәңкәсен банк счетларына язып куйган һәм акча күчергән өчен яңадан санау банк клиенты өстәмә чыгымнар сарыф итәргә мәҗбүр булган аерым, мөстәкыйль хезмәт сыйфатында каралмый.

**Шунлыктан Россия Банкы банк счетларына язып куйган һәм акча күчергән өчен Россия Банкы тәңкәләрен кабул итү һәм яңадан санау хезмәтенә комиссион түләү билгеләүгә юл куярга ярамавына игътибар юнәлтә.**

# Рейс тоткарланса, авиапассажирга нишләргә?

**2021 елның 27 июнендә Кулланучыларның хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте кулланучылар өчен авиарейслар тоткарланган очракта аларның хокуклары турында мәгълүмат тәкъдим итте.**

Рейсның тоткарлануы – авиакомпания гаебе белән авиарейсларда өзеклек барлыкка килү яисә күзгалып киткән яки очыш вакытында самолетның мәҗбүри рәвештә тоткарлануы ул. Самолетның техник яктан төзек булмавы, начар һава шартлары, очкычның аэропортка соң төшүе рейсларның тоткарлану сәбәбе булып тора.



**Рейс тоткарланган очракта пассажир түбәндәгеләргә хокуклы:**

- очудан баш тартырга. Бу мәҗбүри чара булганга, авиакомпания билетны хәтта «кайтарып булмый» торган очракта да авиабилет бәясен кире кайтарырга бурычлы;
- зыянны каплау һәм әхлакый зыянны компенсацияләүгә. Пассажирның рейс тоткарлану сәбәпле күргән зыянны каплау турында дәгъва белән авиакомпаниягә мөрәҗәгать итәргә хакы бар (әйтик, алдан түләп куелган экскурсияләр «янса», пассажир поездга соңга калса һ.б.). Зыянны раслый торган документлар күчермәсен тәкъдим итәргә кирәк. Дәгъва авиакомпаниягә аэропортлардагы җибәрү пунктында яки билгеләнгән пунктта күрсәтелә. Эчке авиарейсларда аны рейс тоткарланган көннән 6 ай эчендә тәкъдим итәргә мөмкин;
- пассажирны билгеләнгән пунктка илтүне кичектергән өчен авиакомпаниядән штраф түләттерүгә. Авиакомпания пассажирны билгеләнгән пунктка илтүне кичектерү аңа бәйле булмаган шартлар аркасында килеп чыгуын раслый алмаган очракта, штрафның күләме һәр сәгать өчен хезмәткә түләүдә минималь күләмнең 25 процентын тәшкил итә, әмма авиабилетның 50 процентыннан да артып китми.

**Кулланучылар консультация, шулай ук авиакомпаниягә дәгъва гаризасы язуда ярдәм сорап Роспотребнадзорның субъект буенча идарәсенә мөрәҗәгать итә ала.**